| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**13.10.2017ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2595** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2017 елның 25 июлендәге 2029 номерлы карарының кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 31 мартындагы 201 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2017 елның 25 июлендәге 2029 номерлы карарының кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган, Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәрдә:

2.7 пунктының унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 елның 24 августындагы 678 номерлы карарына нигезендә тәрбиячеләрнең база оклады (эш хакы ставкасы) мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакының дүрт разрядлы тариф челтәре буенча IV разрядына туры килә.»;

2.9 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$FOT^{t}_{vosvz} = \frac{\left(y \times x \times \left(1/n_{vzвосп} \times b_{восп}\right) \times e \times k_{vвосп} \times 12 + y \times x / n_{vzвосп} \times O_b \times r^t\right)}{m_{vzqlim}}$ x (1+$К_{замещ}$),»;

түбәндәге эчтәлекле ундүртенче абзац өстәргә:

««$К_{замещ}$ - кабул ителә торган биләү коэффициенты2 процентка тигез.»;

2.10 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2010 елның 24 августындагы 678 номерлы карары нигезендә педагог-психологларның база оклады (хезмәт хакы ставкасы) мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакының дүрт разрядлы тариф челтәре буенча IV разрядына туры килә;

2.13 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2010 елның 24 августындагы 678 номерлы карары нигезендә башка педагогик персоналның база оклады (хезмәт хакы ставкасы) шәһәр һәм авыл җирлекләрендәге мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакының дүрт разрядлы тариф челтәре буенча IV разрядына туры килә.»;

2.15 пунктта:

3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3 нче таблица

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында шөгыльләнү төрләре буенча мәктәпкәчә яшьтәге балаларның атналык белем бирү йөкләмәсенең сәгатьләре саны

(1 тәрбияләнүчегә сәгать)

| Шөгыль төрләре | Балаларның атналык белем бирү йөкләмәсенең астрономик сәгатьләр саны | |
|---|---|---|
| | 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән артык |
| Физкультура-савыктыру циклы шөгыльләре | 0,050 | 0,125 |
| Эстетик цикл шөгыльләре | 0,050 | 0,142 |
| Балаларның танып-белү активлыгын һәм акыл киеренкелеген арттыруны таләп итә торган шөгыльләр | 0,050 | 0,190»; |

«$Z_3$» абзацы - балаларның танып белү активлыгын һәм акыл киеренкелеген

таләп итүче шөгыльләргә укытучыларының хезмәт хакы ставкасы өчен сәгатьләр саны (атнага 18 сәгать);» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - $z_3$ балаларның танып белү активлыгын һәм акыл киеренкелеген таләп итә торган шөгыльләргә тәрбиячеләренең хезмәт хакы ставкасы өчен сәгатьләр саны (атнага 36 сәгать);»;

2.16 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2010 елның 24 августындагы 678 номерлы карары нигезендә башка педагогик персоналның база оклады (хезмәт хакы ставкасы) мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакының дүрт разрядлы тариф челтәре буенча IV разрядына туры килә.»;

3.1 пунктта:

5 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5 нче таблица

Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне укыту һәм тәрбия чаралары белән тәэмин итү нормативлары

(данә)

| Предметның исеме | Елына бер тәрбияләнүчегә норма |
|---|---|
| Уеннар, уенчыклар | 12,00 |
| Уеннар өчен инвентарь һәм башка укыту һәм тәрбия чаралары | 5,26»; |

3.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«R_{vy}obes = \sum_{i_1=1}^{n=1} N_{i1\,v\,toy} \times C_{i1toy}\text{,»;}$$

бишенче, алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$N_{i1\,v\,toy}$ - әлеге Методик тәкъдимнәрнең 3.1 пунктында каралганча кабул ителә торган тәрбияләнүчеләрне укыту һәм тәрбия чаралары белән тәэмин итү нормалары;

$C_{i\,1\,toy}$ - әлеге Методик тәкъдимнәрнең 3.1 пункты нигезендә кабул ителә торган укыту һәм тәрбия чараларының бәясе;»;

тугызынчы, унынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип таныырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мөлкәтне тотуга норматив чыгымнарны, коммуналь

хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнарны, элемтә хезмәтләренә норматив чыгымнарны, бассейннарны карап тотуга норматив чыгымнарны исәпләү буенча методик тәкъдимнәрдә:

1.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«дезинфекция буенча хезмәт күрсәтүгә чыгымнар;

җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар»;

1.2 пунктта «1 кв. метрга 1,5 сум» сүзләреннән соң «айга» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 1.4, 1.5 пунктлар өстәргә:

«1.4. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында дезинфекция буенча хезмәт күрсәтүгә чыгымнар җылытыла торган йорт(бина) мәйданының 1 кв.метрына аена 0,24 сум исәбеннән билгеләнә.

1.5. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар җылытыла торган йорт(бина) мәйданының 1 кв.метрына аена 1,15 сум исәбеннән билгеләнә.

2. Учреждение җитәкчеләренә үзләренең локаль норматив актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин